БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 28 » март 2018 ел № 101

"Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында" 2014 елның 21 гыйнварындагы 57 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына Адреслылык принцибын үтәү һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычыннан чыгып, социаль ярдәм чараларын күрсәтүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында" 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. "Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында" 2014 елның 21 гыйнварындагы 57 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

"3. "Россия Федерациясенең аерым закон актларына Адреслылык принцибын үтәү һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычыннан чыгып, социаль ярдәм чараларын күрсәтүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында" 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ташламалар бирә торган органнар Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба — ЕГИССО) куллану юлы белән, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматларга туры китереп, күрсәтелгән ташламалар бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр."

1.2. 3 пунктны 4 пункт дип санарга,

4 пунктны 5 пункт дип санарга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р. И. Шакиров